**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**23 сентябрь 2020 ел** **№ 11**

**«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 16 апрелендәге 143 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» 6.08.2020 ел, № 658 карары, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Уставы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Нурлат муниципаль районы Советының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, контроль-хисап органнары рәисләренә, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 16 апрелендәге 143 номерлы карарына, карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«1. Нурлат муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладының күләменә тигез һәм ул 11 498 сум тәшкил итә дип билгеләргә.».

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга: http://nurlat.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар 2020 елның 1 октябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Советы рәисе А.С. Әхмәтшин